**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "КОДАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**V ЧАКЫРЫЛЫШ**

**ДҮРТЕНЧЕ СЕССИЯ**

**2 нче КАРАР**

Кодаш б. 2025 елның 12 декабре

**45 нче чакырылышның 2 нче карарына**
**үзгәрешләр кертү турында**
**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге Советының**
**2014 елның 25 апрелендәге**
**"Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге Советы**
**Регламенты турында"**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында "26.01.2023 ел, № 1-ТРЗ ТР Законы үз көченә керүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Кодаш авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Советы Регламенты турында» Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 апрелендәге 245 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 29 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек башлыгы яңа сайланган җирлек советының беренче сессиясендә җирлек Советы депутатлары арасыннан яшерен яисә ачык тавыш бирү юлы белән җирлек Советы вәкаләтләре чорына сайлана. Җирлек башлыгын сайлау җирлек Советы депутатлары тарафыннан күрсәтелә торган кандидатлар арасыннан, шул исәптән гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.»

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районының**
**«Кодаш авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге башлыгы Г. Ә. Хәйсарова**